КАРАР (РЕШЕНИЕ)

“Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге составына керүче Байлар Сабасы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

20.11.2020 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлеге Уставының 22 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге Советының 04.10.2019 елның 33 номерлы “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында"гы карарына таянып, 2020 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыенында “2021 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?" мәсьәләсе һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә контейнер мәйданчыклары төзү (материал алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү (материал алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең урам юлларын төзекләндерү һәм вак таш белән түшәү (нигез салу, бетон һәм асфальт түшәү, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең электр тапшыру линияләрен монтажлау (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә агачлар һәм куаклар утырту (үсентеләрне сатып алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 6611 кеше кертелгән, шуның 3451е тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 3319 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 132 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены КАРАР ИТТЕ:

1. “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. “2021 нче елда “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы бистәсе” муниципаль берәмлегенә керүче Байлар Сабасы торак пунктында, яшәү урыны буенча “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсе” муниципаль берәмлегенең Байлар Сабасы торак пункты составына теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 (өч йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә контейнер мәйданчыклары төзү (материал алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең тротуарларын һәм су агу улакларын төзекләндерү һәм төзү (материал алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәнең урам юлларын төзекләндерү һәм вак таш белән түшәү (нигез салу, бетон һәм асфальт түшәү, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәсенең электр тапшыру линияләрен монтажлау (килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- Байлар Сабасы шәһәр тибындагы бистәдә агачлар һәм куаклар утырту (үсентеләрне сатып алу, килешү, муниципаль контракт буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)” карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлегенең рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/saba адресы буенча һәм җирлектә урнашкан мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Саба шәһәр җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Саба шәһәр
җирлеге башлыгы Р.М. Хәсәнов